ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

от 18.11.2020 г. Казань № 236-33/тэ-2020

«Индустриальный парк - Сервис» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык саклау матдәсенә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 23.11.2018 № 5-46/тэ карарында билгеләнгән озак сроклы тарифларга 2021 ел өчен төзәтмә кертү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя кую турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2021 елга җайга салынулы оешманың планлаштырылган кирәкле тулай керемен тәгаенләштереп, 2021 елга җылылык саклау матдәсенә озак сроклы тарифларны төзәтү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2019-2021 елларга «Индустриальный парк - Сервис» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык саклау матдәсенә тарифлар билгеләү хакында» 23.11.2018 № 5-46/тэ карарының 1 нче кушымтасына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 13.11.2019 № 5-13/тэ карары керткән үзгәрешләре белән) үзгәреш кертеп, аны яңа редакциядә (кушымтада бирелә) бәян итәргә.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
23.11.2018 № 5-46/тэ
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.11.2020 № 236-33/тэ-2020
карары редакциясендә)

2019-2021 елларга «Индустриальный парк - Сервис» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан кулланучыларга җиткерелә торган җылылык саклау матдәсенә календарь буенча бүленгән тарифлар

| Т/с | Җайга салынулы оешманың исеме | Тариф төре | Ел | Җылылык саклау матдәсенең төре | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | су | пар |
| | Кулланучыларга җибәрелә торган җылылык саклау матдәсенә тарифлар | | | | |
| | Түбән Кама муниципаль районы | | | | |
| 1 | «Индустриальный парк - Сервис» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | бер ставкалы, сум/куб. м | 01.01.2019 башлап 30.06.2019 кадәр | 141,00 | - |
| | | | 01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр | 144,12 | - |
| | | | 01.01.2020 башлап 30.06.2020 кадәр | 139,80 | - |
| | | | 01.07.2020 башлап 31.12.2020 кадәр | 143,92 | - |
| | | | 01.01.2021 башлап 30.06.2021 кадәр | 143,92 | - |
| | | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 146,23 | - |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге